Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXIII-2**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 сентябре

Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе хакындагы Нигезләмәне раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә,Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 2 декабрендәге “Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районында халык тыңлаулары оештыру һәм үткәрү тәртибе хакындагы Нигезләмәне раслау турында”гы XXXI-2 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 4 сентябрендәге
XXXIII-2 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында**
**Нигезләмә**

Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә)Россия ФедерациясеКонституциясе, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде.

1 Бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1 маддә. Төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр файдаланыла:

**халык тыңлаулары** –җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенчамуниципаль хокук актлары проектларын җәмәгатьчелек тикшерүе аркылыТатарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең карарлар кабул итү процессында, шулай ук федераль законнар, әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән мәсьәләләр буенча фикер алышулардакатнашу хокукларын гамәлгә ашыру формасы;

**инициатив төркем** –Россия Федерациясенеңхалык тыңлауларында катнашуга хокукы булган гражданы яки гражданнары төркеме;

**җәмәгатьчелек вәкиле** – карала торган мәсьәләне тикшерүдә катнашырга хокукы булып халык тыңлауларында катнашучы физик зат, шул исәптән юридик затларның, берләшмәләрнең вәкилләре. Халык тыңлауларына чыгарылган мәсьәләләр буенчаҗирле үзидарә яки дәүләт хакимияте органнары вәкилләре булып торган яисә алар эшчәнлегендә шартнамә нигезендәтүләүле катнашучылар хезмәт вазыйфасына мөнәсәбәтле карарлар кабул итүче затлар буларак җәмәгатьчелек вәкиле була алмыйлар

**халык тыңлауларында катнашучылар** – җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, халык тыңлауларының экспертлары, халык тыңлаулары үткәрү буенча оештыру комитеты әгъзалары;

**чыгыш ясарга хокуклары булган халык тыңлауларында катнашучылар**

– халык тыңлаулары мәсьәләләре буенча чыгыш ясарга үзләренең гаризаларын әлеге Нигезләмәнең 7 маддәсендә билгеләнгән срокларда оештыру комитетына тапшырган җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре;

**оештыру комитеты –** муниципаль районның җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларыннан, муниципаль район Советы депутатларыннан, җәмәгатьчелек һәм гражданнарның инициатива төркемнәре вәкилләреннән бердәй дәрәҗәдә оештырылган халык тыңлауларын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру эшләрен гамәлгә ашыручы коллегиаль орган;

**җәмәгатьчелек фикер алышулары –** иҗтимагый әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне, шулай ук җирле үзидарә органнарының карарлары проектларын мондый фикер алышуларда мәнфәгатьләренә тиңдәшле карарлар кагыла торган җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның, гражданнар вәкилләре һәм иҗтимагый берләшмәләрнең вәкаләтле затларының мәҗбүри катнашындагы халык тикшерүенә җәмәгать контроле максатларында файдаланыла торган ачык фикер алышу;

**халык тыңлаулары эксперты –** халык тыңлаулары мәсьәләләре буенчамахсус белемнәргә ия булыпбу статуска вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән зат.Эксперт халык тыңлаулары мәсьәләләре буенча язмача рәвештә тәкъдим һәм киңәшләрен тәкъдим итә һәм аларны нигезләү өчен фикер алышуларда катнаша.

## 2 маддә. Халык тыңлаулары үткәрүнең максатлары

Халык тыңлаулары түбәндәге максатларда үткәрелә:

муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенчамуниципаль районда яшәүчеләр катнашында мәҗбүри тәртиптә халык тыңлауларына чыгарылучы муниципаль хокукый актлар проектларын тикшерүләр;

халык тыңлауларына чыгарылучы мәсьәләләр буенча җәмәгатьчелек фикерен тикшереп белү һәм исәпкә алу;

халык тыңлауларын әзерләү, үткәрү һәм нәтиҗәләрен билгеләү ачыклык, хәбәрдарлык, иреклелек һәм экспертларның бәйсезлеге принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 3 маддә. Халык тыңлауларына чыгарылучы мәсьәләләр

1.Халык тыңлаулары җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләр буенча үткәрелә. Халык тыңлауларының нәтиҗәсе җирле үзидарә органнары өчен киңәш сыйфатында була.

2.Халык тыңлауларына мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1)муниципаль районның Устав проекты (алга таба – Устав), шулай ук муниципаль район Советының Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләркертү (Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки законнары нигезләмәләренең төгәл күчермәләре формасындабу норматив-хокукый актларына Уставны яраклаштыру максатларында Уставка үзгәрешләр кертү очрагыннан гайре) турындагы карар проекты;

2)җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3)муниципаль районның социаль-икътисади үсеш стратегиясе проекты;

4)муниципаль районны үзгәртү турында мәсьәләләр,“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсе нигезендә муниципаль районны үзгәртү өчен муниципаль район халкының тавыш бирүе яисә гражданнар җыеннарында бирелгән ризалыгы таләп ителгән очрактан гайре;

5)генераль план проекты, җирдән файдалану һәм төзүләр кагыйдәләре, территорияләрне планлаштырупроекты, территорияләргә ызанлау проекты, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күз алдында тоткан проект, җир кишәрлеген файдалануга яки капиталь төзелешобъектына шартлы рөхсәт рәвешендә рөхсәт бирү турындагы карар проекты, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү турындагы карар проекты, җирдән файдалануның һәм төзүләрнең расланган кагыйдәләре булмаганда җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт белән файдалануның бер төрен шундый ук файдалануның икенче төренә үзгәртү мәсьәләсе;

6)ачык сервитутлар (йөкләмәләр) билгеләү мәсьәләләре;

7)җылылык белән тәэмин итү схемалары проекты;

8)федераль законнар тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләр.

3.Һәр мәсьәлә буенча төрлеяклап һәм тулы фикер алышуга комачаулык тумаса, берничә мәсьәлә буенча халык тыңлауларын бер үк вакытта үткәрү рөхсәт ителә.

4.Россия Федерациясе законнары тарафыннан башкача билгеләнмәсә, халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү җирле бюджет средстволары хисабыннан финанслана.

### 4 маддә.Халык тыңлаулары инициаторлары

Халык тыңлаулары халык,муниципаль район Советы (алга таба – Совет), муниципаль район башлыгы (алга таба – Башлык) инициативасы белән үткәрелә.

Халык тыңлауларын үткәрү буенча халык инициативасы 18 яшькә җиткән һәм саны 50 кешедән ким булмаган гражданнар төркеменнән чыгарга мөмкин.

## 2 бүлек.ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫН БИЛГЕЛӘҮ

### 5 маддә. Халык тыңлауларын билгеләү

1. Халык яки Совет инициативасы буенча үткәрелүче халык тыңлаулары Совет карары белән билгеләнә.

Башлык инициативасы буенча үткәрелүче халык тыңлаулары Башлык тарафыннан билгеләнә.

Халык тыңлаулары Россия Федерациясе законнары тарафыннан җирле

үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча үткәрелә.

2.Халык тыңлауларын үткәрү турында халык инициативасын тәкъдим итү һәминициативаны хуплауга халыктан имзалар җыю өчен 10 кешедән дә ким булмаган сандагы инициативатөркеме булдырыла.

2.1.Инициативатөркеме Советка тәкъдим итә:

- халык тыңлаулары мәсьәләсен күрсәтеп һәм аларны үткәрүнең зарурлыгын нигезләп, гражданнар инициатива төркеменең вәкаләтле вәкиле имзалаган халык тыңлауларын билгеләү турында 1 номерлы кушымтага ярашлы форма буенча гаризаны;

-муниципаль хокукый акт проектын (аның халык тыңлаулары каравына кертелү очрагында);

-максатларын һәм төп нигезләмәләрен күрсәтеп, муниципаль хокукый актны кабул итүнең зарурлыгын дәлилләүне үз эченә алган аңлатма язуын (аның халык тыңлаулары каравына кертелү очрагында);

- финанс-икътисади яктан нигезләүне (тормышка ашыруы өстәмә матди һәм башка чыгымнар сорый торган муниципаль хокукый актныңхалык тыңлаулары каравына кертелү очрагында);

-2 номерлы кушымтага ярашлы форма буенчагражданнар инициатива төркеменең исемлеген;

- гражданнар инициатива төркемен төзү турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсен;

- инициатива төркеме тарафыннан тәкъдим ителүче битләр саны күрсәтелгән документларның исемлеге, шулай ук муниципаль хокукый акт проектының докладчысы турында мәгълүмат белән бергәинициатива төркеменең вәкаләтле вәкиле имзалаган бергә җибәрелүче хатны (муниципаль хокукый актныңхалык тыңлаулары каравына кертелү очрагында).

Гариза һәм беркетмә рәислек итүче (гражданнар инициатива төркеменең вәкаләтле вәкиле) һәм инициатива төркеме җыелышының сәркатибе тарафыннан имзаланган булырга тиеш.

2.2.Әлеге маддәнең 2.1 пунктчасында билгеләнгән барлык документлар да бер үк вакытта Советка тапшырылса, гариза бирелгән дип санала.

2.3.Гариза һәм аңа теркәлгән документларның Советка кергән көненнән календарь көннәрдә исәпләнүче утыз көнлек срокта инициатива төркеме тарафыннан халык тыңлаулары үткәрү инициативасын хуплаучы халыкның имзалары җыйналырга һәм тапшырылырга тиеш – 3 номерлы кушымтага ярашлы форма буенчамуниципаль районда 18 яшькә җиткән яшәүчеләрнең 50 дән дә ким булмаган санда имзалары.

Халык тыңлауларын үткәрү турында инициатива күрсәтү хакындагы гаризаны Советка бирү көне артыннан килүче көннән башлап имзаларны җыярга мөмкин. Имзалар җыю кәгазенә мәгълүматларны кульязмалы булмаган ысул яисә карандаш белән кертү рөхсәт ителми.Гражданнар турында тиндәшле мәгълүматларда һәм аларны имзалар җыю кәгазенә кертү даталарында һәм раслау язмаларындагы төзәтүләр мәсьәләсендә гражданнар һәм имза җыючылар белән алдан тиешенчә сөйләшенеп куелырга тиеш.

2.4.Совет эшче төркем төзи һәм имзалар җыю кәгазьләре тапшырылган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнгән ун көнлек срокта имза җыю кәгаьләрендәге китерелгән мәгълүматларны тикшерү үткәрә.Имзаларны һәм имза җыю кәгазьләрендәге мәгълүматларны тикшерү нәтиҗәләре буенча имза дөрес яисә дөрес түгел дип танылырга мөмкин. Әлеге Нигезләмә нигезендә дөрес түгеллеге расланмаса, имза дөрес була.

Имзалар дөрес түгел дип, ягъни имзаларны җыю тәртибен һәм (яки) имза җыю кәгазен рәсмиләштерүне бозып җыелган имзалар дип танылалар:

1)имзалар җыю чорыннан тыш җыелган имзалар;

2)муниципаль районның 18 яшькә җитмәгән кешеләренең имзалары;

3)имзасын имзалар җыю кәгазенә үз кулы белән кертү датасын күрсәтмәгән гражданнарның имзалары;

4)мәгълүматлары имзалар җыю кәгазенә кульязмалы булмаган ысул яисә карандаш белән кертелгән имзалар;

5)гражданнар турында тиңдәшле мәгълүматларда һәм аларны имзалар җыю кәгазенә кертү даталарында төзәтүләр булган имзалар, әгәр бу төзәтүләр мәсьәләсендә гражданнар, имза җыючылар тарафыннан алдан махсус сөйләшенеп куелмаган булса;

6)әлеге Нигезләмәгә бирелгән 3 номерлы кушымта таләпләренә туры килмәгән формадагы имза җыю кәгазенең бөтен имзалары.

Тикшерү нәтиҗәләре имза җыю кәгазьләрен тикшерү беркетмәсе белән рәсмиләштерелә (4 номерлы кушымта).

2.5.Имза җыю кәгазьләре кергән көннән соң календарь көннәрдә исәпләнүче унбиш көнлек срокта Советның чираттагы утырышында халык тыңлауларын билгеләү турында карар кабул ителә яисә халык тыңлауларын билгеләү турындагы гаризаны түбәндәге очракларда кире кагу хакында карар кабул ителә, әгәр:

1)халык тыңлауларына чыгарылучы мәсьәләләр,әлеге Нигезләмәнең 3 маддәсендә каралган очраклардан гайре, җирле үзидарә органнары компетенциясенә кермәсә;

2)тапшырылган дөрес имзаларның саны халык тыңлаулары үткәрү турында халык инициативасын күрсәтү өчен җитәрлек булмаса;

3) инициативаны күрсәтү тәртибе үтәлмәгән булса;

4)карауга тәкъдим ителә торган муниципаль норматив-хокукый акт проекты Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләренә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга, башка норматив-хокукый актларга туры килмәсә;

5)шундый ук мәсьәлә чыгарылган халык тыңлаулары үткәрелгән датадан соң бер елдан әзрәк вакыт үтсә.

2.6.Халык тыңлауларын билгеләү турындагы гаризаны кире кагу инициатива төркеменә халык тыңлауларын билгеләү өчен кире кагуга китергән бозуларны бетерү шарты белән документларны кабаттан кертүгә киртә булып тормый.

2.7.Халык тыңлауларын билгеләү турындагы мәсьәлә Совет тарафыннан Совет регламенты нигезендә карала.

2.8.Халык тыңлауларын билгеләү турындагы гаризаны кире каккан очракта Совет эш көннәре белән исәпләнүче биш көнлек срокта гражданнарның инициатива төркеменең вәкаләтле вәкиле исеменә язмача дәлилле хәбәрнамә җибәрә.

3.Халык тыңлауларын билгеләгән Совет, Башлык тыңлаулар үткәрүнең мәсьәләсе, сроклары,вакыты һәм урыны , оештыру комитетының составы, халык тыңлауларына чыгарылучы муниципаль хокукый акт проектын тикшерүдә гражданнарның катнашуын һәм тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе турындагы мәгълүматлары булган тиешле муниципаль актларны кабул итәләр.

Халык тыңлауларын үткәрү датасы халык тыңлауларын билгеләү турында муниципаль хокукый акт кабул ителгән көннән календарь көннәр белән исәпләгәндә утыз көнлек срокта билгеләнә, әгәр федераль законнар, Устав һәм әлеге Нигезләмә белән башкасы билгеләнмәгән булса.

6 маддә. Халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) турында хәбәр итү

1.Муниципаль район халкына халык тыңлауларын билгеләү турында хәбәр итү халык тыңлауларын үткәрү көненә кадәр календарь көннәр белән исәпләнгән ун көнлек срокта (әгәр федераль законнар, Устав һәм әлеге Нигезләмә тарафыннан башкасы каралмаган булса) кушымта итеп бирелгән фикер алыша торган муниципаль хокукый акт проекты белән (халык тыңлаулары каравына аның кертелү очрагында) халык тыңлауларын үткәрү турындагы муниципаль хокукый актны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару, муниципаль районның http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – муниципаль районныңрәсми сайты) һәм (яки) бүтән мәгълүмат системаларында мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

1.1.Халык тыңлауларының нәтиҗәләремассакүләм мәгълүмат чараларында, муниципаль районныңрәсми сайтындаһәм (яки) бүтән мәгълүмат системаларында һәм мәгълүмат стендларында игълан ителә.

Мәгълүмат стендлары әйбәт күренә торган урыннарда мәгълүмат белән файдаланучыларның алар янына үтүен тәэмин итү мөмкинлеген истә тотып җиһазлана.

Мәгълүмат стендларын урнаштырумәгълүмат белән файдаланучының эргономика таләпләре нигезендә озак вакыт мәҗбүри рәвештә уңайсыз гәүдә торышында булу зарурлыгына мөмкинлек калдырмаслык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.

Мәгълүмат стендларын төсләр белән бизәү эстетика таләпләренә туры килергә тиеш.Мәгълүмат стендлары мәгълүматлы кәгазь битләре урнаштыру өчен А4 форматындагы кесәләр белән җиһазландырылырга мөмкин.

2. Халык тыңлауларында яисә җәмәгатьчелек фикер алышуларында каралырга тиешле проект экспозициясен уздыру мәйданчыгы, шулай ук проект экспозициясен караучыларга консультация бирү вакыты килешү буенча халык тыңлаулары яисә җәмәгатьчелек фикер алышулары турында хәбәр итүләргә кертелә.

Экспозициянең эшләү чорында килүчеләр өчен консультацияләр, проект турында басма мәгълүмати материаллар тарату оештырыла. Экспозициягә килүчеләр фикер алыша торган проектка, мәсьәләгә экспозициягә

килүчеләрнеисәпкә алу һәм тәкъдим, фикерләрне язу өчен булган тиешле кенәгәгә (журналга) язмача рәвештә үзләренең тәкъдимнәрен, фикерләрен кертергә хокуклы.

Проект экспозициясендә тәкъдим ителә:

- проект;

- проектка аңлатма язуы;

-Россия Федерациясе законнары һәм бүтән норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә алынган документларны килештерү күчермәләре;

-проект буенча халык тыңлаулары яки җәмәгатьчелелек фикер алышулары үткәрү турында, массакүләм мәгълүмат чарасының мәгълүматларын күрсәтеп, бастырылган мәгълүмати хәбәр күчермәсе;

-фикер алыша торган проект буенча гражданнарга мәгълүмат җиткерү максатларында башка информацион һәм демонстрацион материаллар (андый материаллар проектны әзерләүне (эшләүне) оештыручы тарафыннан тәкъдим ителгән очракта).

## 3 бүлек. ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫН ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ ҮТКӘРҮ

### 7 маддә. Халык тыңлауларын әзерләү һәм үткәрүне оештыру

1.Халык тыңлаулары муниципаль район халкы өчен уңайлы вакытта үткәрелә (халык тыңлауларын эшләми торган көннәрдә 11.00 дән 18.00 сәгатькә кадәр яисә эш көннәрендә 17.00 сәгатьтә башлап һәм 22.00 сәгатьтән дә соңга калмыйча тәмамлап).

2.Халык тыңлауларын билгеләү турында карар кабул иткән җирле үзидарә органы муниципаль районның вәкиллекле органыдепутатлары, муниципаль район башкарма комитеты хезмәткәрләре, җәмәгать оешмалары, гражданнарның инициатива (әгәр халык тыңлаулары үткәрүнең инициаторы гражданнарның инициатива төркеме булса) төркеме вәкилләре арасыннан 5 кешедән дә ким булмаган санда оештыру комитеты төзи. Оештыру комитеты төзелгән көненнән эш көннәре белән исәпләнгән 3 көннән дә соң булмаган срокта үтә торган беренче утырышында үз составыннан рәисен, рәис урынбасарын һәм сәркатипне сайлап куя. Оештыру комитеты утырышта әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашканда карарлар кабул итәргә вәкаләтле була.

Оештыру комитеты тыңлаулар үза торган бинага тыңлауларда катнашырга теләк белдерүчеләргә тоткарлыксыз үтүне тәэмин итәргә бурычлы.

Халык тыңлаулары үтә торган көндә оештыру комитеты халык тыңлауларында катнашучыларны теркәүне оештыра.

3. Халык тыңлауларында оештыру комитеты рәисе рәислек итә. Рәислек итүче халык тыңлауларын ачып җибәрә, халык тыңлаулары мәсьәләсен (мәсьәләләрен), тыңлауларны үткәрү тәртибе буенча тәкъдимнәрне игълан итә, үзен, сәркатипне һәм экспертларны тәкъдим итә, тыңлауларны үткәрү инициаторларын күрсәтә. Оештыру комитеты сәркатибе халык тыңлаулары беркетмәсен алып бара.

4. Рәислек итүче фикер алышу үткәрелә торган сорауны игълан итә һәм халык тыңлауларын үткәрү инициаторларының вәкаләтле затына, экспертларга, шулай ук

чыгыш ясарга хокуклы булган халык тыңлауларында катнашучыларга сүзне бирә.Чыгыш ясау чиратлылыгы оештыру комитеты тарафыннан теркәлгән гариза бирү чиратлылыгы белән билгеләнә.

5. Тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән экспертлар да, үзләренең тәкъдим-киңәшләрен алырга һәм (яки) башка халык тыңлауларында катнашучылар тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәргә кушылырга хокуклы.Фикер алышу йомгаклары буенча халык тыңлауларына чыгарылган, халык тыңлауларында катнашучылар тарафыннан алынган тәкъдим һәм киңәшләрдән гайре, җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итү буенча тәкъдим һәм киңәшләрнең бердәм исемлеге төзелә.

6. Тәкъдимнәр һәм киңәшләр белән йомгак документын төзегәннән соң рәислек итүче җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итүнең йомгаклау вариантын катнашучыларның тавыш бирүенә куя.Халык тыңлауларында карарлар ачык тавыш бирү юлы белән теркәлгән тыңлауларда катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Һәрбер тыңлауларда катнашучы бер тавышка ия һәм ул аны җирле әһәмияттәге мәсьәләнең тәкъдим ителгән хәл ителеше өчен яки аңа каршы бирә яисә тавыш бирүдән тыелып кала. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә. Беркетмәне рәислек итүче һәм халык тыңлауларының сәркатибе имзалый.

7.Халык тыңлаулары беркетмәсе нигезендә халык тыңлаулары үткәрелгән көннән эш көннәре белән исәпләнүче өч көнлек срокта халык тыңлаулары йомгаклары буенча нәтиҗә төзелә (6 номерлы кушымта), анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) халык тыңлауларына чыгарылган мәсьәлә (мәсьәләләр) ;

2) халык тыңлауларын үткәрүнең инициаторы;

3) халык тыңлауларын билгеләү турындагы хокукый актның датасы, номеры һәм исеме, шулай ук аны бастырып чыгару (халыкка игълан итү) датасы;

4) халык тыңлауларын үткәрүнең датасы, вакыты һәм урыны;

5) халык тыңлауларын үткәргән оештыру комитеты;

6) халык тыңлауларында катнашучылар турында , шул исәптән чыгыш ясарга хокук алганнар турында мәгълүмат;

7) халык тыңлауларына чыгарылган җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итү буенча, халык тыңлауларында катнашучылар тарафыннан алынганнарыннан гайре,тәкъдим һәм киңәшләрнең бердәм исемлеге;

8) җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты;

9) халык тыңлауларында атнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре.

8.Халык тыңлауларының йомгаклары турында нәтиҗә оештыру комитетының рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана һәм халык тыңлауларын үткәрү көненнән эш көннәре белән исәпләнгән 3 көнлек срокта бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

9.Халык тыңлаулары йомгаклары буенча нәтиҗә халык тыңлауларына чыгарылган мәсьәләләр буенча карар кабул итүгә җаваплы булган җирле үзидарә органы тарафыннан мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш. Мәҗбүри тәртиптә карау йомгаклары халык тыңлаулары йомгаклары турындагы нәтиҗәне җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан карау көненнән эш көннәре белән исәпләнгән 3

көнлек срокта бастырып чыгару (халыкка игълан итү) юлы белән халык тыңлаулары инициаторларына, муниципаль район халкына җиткерелә.

10.Халык тыңлаулары йомгаклары турында нәтиҗә, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очраклардан гайре, тәкъдим итү, киңәш бирү үзенчәлегенә ия.

## 4 бүлек.МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН УСТАВЫ ПРОЕКТЫ, УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА СОВЕТ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ, ҖИРЛЕ БЮДЖЕТ ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛЕШЕ ТУРЫНДА ХИСАП ПРОЕКТЫ, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫ ҮЗГӘРТҮ ТУРЫНДАГЫ МӘСЬӘЛӘ, МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАННАРЫ ПРОЕКТЛАРЫ БУЕНЧА ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

### 8 маддә. Халык тыңлауларындамуниципаль район Уставы проектын һәм Уставка үзгәрешләр кертү турында Совет карары проектын карау үзенчәлекләре

1.Устав проекты һәм Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты халык тыңлауларында 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” гы 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Уставта каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып карала.

2.Устав проекты һәм Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты Совет тарафыннан аны кабул итү турындагы мәсьәлә каралу көненә кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш. Бер үк вакытта күрсәтелгән проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, аны тикшерүдә гражданнарның катнашу тәртибе, шулай ук проект буенча халык тыңлаулары билгеләү турында Совет карары игълан ителә.

Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен Уставка үзгәрешләр Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләренең төгәл күчермәсе рәвешендә Уставны әлеге норматив-хокукый актлар белән ярашлы итү максатларында кертелү очрагындарәсми төстә бастырып чыгару (халыкка игълан итү) таләп ителми.

.3.Устав проекты яки Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты буенча халык тыңлаулары Устав белән билгеләнгән, ләкин күрсәтелгән проектларны игълан иткәннән соң 10 календарь көннән дә алдан булмаган срокларда үткәрелә.

4.Устав проекты яки Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты буенча халык тыңлаулары үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

### 9 маддә.Халык тыңлауларында җирле бюджет проектыһәм аның үтәлеше турында хисапны карау үзенчәлекләре

1. Җирле бюджет проектыһәм аның үтәлеше турында еллык хисап халык тыңлауларында Россия Федерациясе Бюджет кодексы, башка федераль законнар, Устав, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында бюджет процессы турында”гы Нигезләмә белән каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып карала.

2.Җирле бюджет проектыһәм җирле бюджетның үтәлеше турында хисап буенча халык тыңлауларын үткәрүне гамәлгә ашыручы орган булып оештыру комитеты тора.

Җирле бюджет проектыһәм җирле бюджетның үтәлеше турында хисап буенча халык тыңлауларын билгеләү турында карар кабул итүче орган булып муниципаль район Советы тора.

3.Җирле бюджет проекты, җирле бюджетның үтәлеше турында хисап буенча халык тыңлауларын билгеләү турында карарлар аларны кабул иткәннән соң календарь көннәр белән исәпләнгән 10 көнлек срокта игълан ителергә тиеш.

4.Җирле бюджет проекты, җирле бюджетның үтәлеше турында хисап буенча халык тыңлаулары җирле бюджет проектын (җирле бюджетның үтәлеше турында хисапны) игълан иткәннән соң 15 календарь көннән дә алда үткәрелми.

10 маддә. Халык тыңлауларында муниципаль районның социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын карау үзенчәлекләре

Муниципаль районның социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектына караган мәсьәләләр халык тыңлауларына 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2014 елның 28 июнендәге “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында” гы 172-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып чыгарыла.

11 маддә. Халык тыңлауларында муниципаль районны үзгәртү турындагы мәсьәләне карау үзенчәлекләре

1. Муниципаль районны үзгәртү турындагы мәсьәлә буенча халык тыңлаулары 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсендә каралган, күрсәтелгән Федераль законның 13 маддәсе 5 өлешеннән гайре, очракларда үткәрелә.

3.Муниципаль районны үзгәртү турындагы мәсьәлә буенча халык тыңлауларын үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

12 маддә. Муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча мәсьәләләрне җәмәгатьчелек фикер алышуларында, халык тыңлауларында карау үзенчәлекләре

Генераль планнар проектларына, җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре

проектларына, территорияләрне планлаштыру проектларына, территорияләрне ызанлау проектларына, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектларына, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектларга, җир кишәрлеге яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карарлар проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында карарлар проектына, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларынан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен җирдән файдалану һәм төзүнең расланган кагыйдәләре булмаганда шундый ук файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләләренә кагылган сораулар Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып шулай ук җәмәгатьчелек фикер алышуларына чыгарылырга мөмкин.

Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округлары генераль планнары проектлары буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары, халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләре Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 28 маддәсендә китерелә.

Җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертү каралган проектлар буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә халык тыңлаулары (алга таба – җәмәгатьчелек фикер алышулары яки халык тыңлаулары) муниципаль берәмлекнең һәрбер торак пунктында үткәрелә.

Җәмәгатьчелек фикер алышулары яки халык тыңлауларын үткәргәндә җәмәгатьчелек фикер алышулары яки халык тыңлауларында катнашучыларны җәмәгатьчелек фикер алышулары яки халык тыңлауларында катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатларында торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин.

Муниципаль берәмлек халкына җәмәгатьчелек фикер алышулары яки халык тыңлаулары үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып җәмәгатьчелек фикер алышулары яки халык тыңлаулары йомгаклары турында нәтиҗәне игълан итү көненә кадәр аларны үткәрү срогы муниципаль берәмлек уставы һәм муниципаль берәмлек Советының норматив-хокукый акты белән билгеләнә һәм ул бер айдан кимрәк һәм өч айдан артыграк була алмый.

Җирле хакимият башлыгы җәмәгатьчелек фикер алышулары яки халык тыңлаулары йомгаклары турында нәтиҗәне исәпкә алып карар кабул итә:

1)генераль план проекты белән килешү һәм аны муниципаль берәмлек Советына җибәрү турында;

2)генераль план проекты кире кагу һәм аны эшләп бетерүгә җибәрү турында.

13 маддә.. Җәмәгать сервитутлары билгеләү буенча халык тыңлаулары үткәрү үзенчәлекләре

1.Җәмәгать сервитутлары билгеләү буенча халык тыңлауларында катнашу хокукына территориясендә җәмәгать сервитуты билгеләү күздә тотылганмуниципаль берәмлектә даими яисә күбесенчә яшәүче тыңлаулар көненә 18

яшькә җиткән һәрграждан ия.

Гражданнарның халык тыңлауларында катнашуы ирекле нигездә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан иҗтимагый берләшмәләр, милекнең барлык формаларының коммерциячел булмаган һәм коммерция оешмалары халык тыңлауларында катнашучылар була алалар.

2.Халык тыңлаулары вәкаләтле орган яисә 13 маддәнең 1 пунктында күрсәтелгән физик һәм юридик затлар инициативасы буенча үткәрелә.

. Халык тыңлауларын үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

3.Вәкаләтле орган халык тыңлауларын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән 7 эш көне эчендә аларны үткәрү турында муниципаль районның муниципаль актларын игълан итү өчен билгеләнгән рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында игълан бастыра.

Халык тыңлауларының ачылышы алдыннан катнашучыларны мәҗбүри теркәү уздырыла. Теркәгәндә күрсәтелә:

юридик зат өчен – тулы исеме, юридик затның дәүләт теркәве мәгълүматлары;

индивидуаль эшмәкәр өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм гражданның индивидуаль эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәве мәгълүматлары;

физик зат өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме, тору урынының адресы.

4.Халык тыңлауларының нәтиҗәсе халык тыңлауларының үтү датасы һәм урыны, катнашучыларның һәм тыңлауларда булучыларның саны, халык тыңлаулары рәисенең һәм сәркатибенең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, чыгышларның эчтәлеге, тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар күрсәтелгән беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм халык тыңлауларының рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана. Беркетмәгә халык тыңлауларында катнашучыларының исемлеге теркәлә.

5.Җәмәгать сервитутын булачак билгеләү турындагы халык тыңлаулары нәтиҗәләре вәкаләтле орган тарафыннан карала һәм җәмәгать сервитутын билгеләү өчен кирәкле документларга теркәлә.

Җәмәгать сервитутларын билгеләү буенча халык тыңлаулары беркетмәләрен саклау срогы – өч ел. Җәмәгать сервитутларын билгеләү буенча халык тыңлаулары беркетмәләрен саклау өчен җаваплы булып вәкаләтле орган җитәкчесе тора.

14 маддә.. Халык тыңлауларында җылылык тәэмин итү схемасы проектын карау үзенчәлекләре

1.Җылылык тәэмин итү схемасы проекты буенча халык тыңлаулары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге “Җылылык тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр турында”гы 154 номерлы карары белән каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

---

Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта №1

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы
______________________________

**ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫН БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА ГАРИЗА**

_____кешедән торган инициатива төркеме, исемлек теркәлә,_________________
_________________________муниципаль берәмлеге халкы инициативасы белән
___________________________________________________________________
мәсьәләсе буенча халык тыңлаулары билгеләргә тәкъдим итә.

Халык тыңлауларын үткәрүнең зарурлыгын нигезләү:________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

Кушымта (чынбарлыкта тәкъдим ителүче документлар күрсәтелә):

1) муниципаль хокукый акт проекты(кертелү очрагында);

2) аңлатма язуы;

3) финанс-икътисади яктан дәлилләү (тормышка ашыру өчен матди һәм бүтән чыгымнар сорала торган муниципаль хокукый акт кертелү очрагында);

4) гражданнарның инициатива төркеменең исемлеге;

5) гражданнарның инициатива төркемен төзү турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсе;

6) бергә җибәрелүче хат.

Гражданнарның инициатива төркеменең
вәкаләтле вәкиле ______________ ______________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Гражданнарның инициатива төркеменең
сәркатибе_____________ ______________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта №2

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы
_________________________________

**ИНИЦИАТИВА ТӨРКЕМЕ ӘГЪЗАЛАРЫНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ**

| № п/п | Фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм туган елы (18 яшьтәгеләрнең туу числосы һәм ае) | Яшәү урынының адресы | Паспорт мәгълүматлары:шәхесне раслаучы документның сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән | Шәхси имза |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданнарның инициатива
төркеменең вәкаләтле вәкиле _______________ _______________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә
кушымта №3

**ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫНЫҢ ИМЗА ҖЫЮ КӘГАЗЕ**

“________________________________________________________________________________________________________________________”

мәсьәләсе буенча.

Без, түбәндә кул куючылар, ________________________________муниципаль берәмлектә яшәүчеләр инициативасы буенча “___________________________________

_________________________________________________________________________”

мәсьәләсе буенча халык тыңлаулары үткәрүне хуплыйбыз.

| № п/п | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | 18 яшьтәгеләрнең туган елы (өстәп туу числосы һәм ае) | Яшәү урынының адресы | Гражданның паспорты яки аны алыштыручы документның сериясе һәм номеры | Шәхси имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Имза җыю кәгазен таныклыйм:

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

(Фамилиясе, исеме, атасының исеме,гражданның паспортыякиаины алыштыручы документның сериясе һәм номеры, бирү вакыты, аны бирүче органның исемен яки кодын күрсәтеп, имза җыючының тору урынының адресы, аның имзасы һәм аны кертү датасы).

Гражданнарның инициатива
төркеменең вәкаләтле вәкиле ________________ ________________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта №4

**ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫНЫҢ ИМЗА ҖЫЮ КӘГАЗЬЛӘРЕН ТИКШЕРҮ БЕРКЕТМӘСЕ**

“_______________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
___”

мәсьәләсе буенча.

Халык тыңлауларын үткәрү инициативасын хуплаучы гражданнарның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына тапшырылган имзалары саны _______________________________________________________________.

_______________сайлаучының имзасы тикшерелде, шуларның дөрес түгел дип танылды: __________түбәндәге сәбәпләр буенча:

_______________________________________________________________________;

_______________________________________________________________________.

Дөрес түгел дип танылган имзалар саны - ___________________________________.

Дөрес имзаларның гомуми саны чынбарлыкта Советка тапшырылган имзаларның____________% ын төзи..

Эшче төркемнең җитәкчесе __________________ ____________

(имза) (Ф.И.А.и..)

Эшче төркемнең әгъзалары _______________________ ____________________

(имза) (Ф.И.А.и..) _________________

(имза) (Ф.И.А.и..) ____________________________

(дата, вакыт)

Гражданнарның инициатива
төркеменең вәкаләтле вәкиле _______________ _______________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Гражданнарның инициатива
төркеменең сәркатибе
(имза) (Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта №5

**ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫ БЕРКЕТМӘСЕ**

“____” ______________ 20__ ел. № _____

___________ штп.

Халык тыңлаулары

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

_______________________________________ инициативасы буенча билгеләнде

____________________________________________________________________________

_________________________________________________ ____________ № _____

(муниципаль хокукый акт)

___________________________________________________________________________

(муниципаль хокукый актның исеме)

бастырылды

(халыкка игълан ителде):__________________________________________________

үткәрелде___________________________________________________________

_______________________________________________________________ адресы буенча

____________________________________.__________________________________

(үткәрү датасы)

Оештыру комитеты ____________________________________________________

Катнаштылар: ________________________________________________________

Рәислек итүче: _______________________________________________________

Сәркатип: ____________________________________________________________

Экспертлар: __________________________________________________________

Халык тыңлауларында катнашучылар(теркәлгән катнашучылар саны):

_____________________________________________________________

Халык тыңлауларында чыгыш ясаучы катнашучылар:

___________________________________________________________________________

(Ф.И.А.и

Тыңланды:

1.________________________________________________________________

(Ф.И.А.и

2. ________________________________________________________________

(Ф.И.А.и)

3. ________________________________________________________________

(Ф.И.А.и.)

Телдән һәм язмача рәвештә кертелгән киңәш һәм тәкъдимнәр саны__________, шул исәптән:

| № п/п | Киңәш һәм тәкъдимнәр | Мөрәҗәгать итүче |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Халык тыңлауларында рәислек итүче_____________ ______________________
(имза)(Ф.И.А.и.)

Халык тыңлауларының сәркатибе______________________ ______________________
(имза)(Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы“ муниципаль берәмлегендә халык тыңлаулары (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта №6

## ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА НӘТИҖӘ

“___”_____ _________ 20__ ел. . ___________штп.

Халык тыңлаулары

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

______________________________________ инициативасы буенча билгеләнде

___________________________________________________________________________

________________________________________________ ____________ № _____

(муниципаль хокукый акт)

___________________________________________________________________________

(муниципаль хокукый актның исеме)

бастырылды

(халыкка игълан ителде):_____________________________________________

үткәрелде__________________________________________________________

_______________________________________________________ адресы буенча

__________________________________.________________________________

(үткәрү датасы)

Халык тыңлауларына чыгарылган мәсәләләләләр____________________________

Халык тыңлауларын үткәрү инициаторы ________________________________________

Халык тыңлауларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны ___________________________

_______________________________________________________________

Халык тыңлауларын үткәрүче оештыру комитеты________________________________

Халык тыңлауларында катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясауга хокук алучылар турында мәгълүмат_________________________________________________________

Халык тыңлауларына чыгарылган җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итү буенча тәкъдим һәм киңәшләрнең бердәм исемлеге

| Фикер алышуга чыгарылган мәсьәләләр | | Эксперт һәм катнашучыларның тәкъдимнәре һәм киңәшләре | | Тәкъдимнәр киңәшләр) кертелде хупланды) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| № п/п | Мәсьәләне тәгъбирләү яки проект исеме | № п/п | Тәкъдимнең тексты | Экспертның катнашучының ) Ф.И.А.и. | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | 1.1 | | | |
| | | 1.2 | | | |
| 2 | | 2.1 | | | |
| 3 | | 2.2<br>3.1<br>3.2 | | | |

Җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты: ______________________________

Халык тыңлауларында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре:

яклап ______________________ (кеше)
каршы__________________ (кеше)
тыелып калучылар____________ (кеше)

Оештыру комитеты рәисе ______________________________

Оештыру комитеты сәркатибе ________________________________